КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 июль г.Казань № 629

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2018 ел, 12 май, 350 нче; 2018 ел, 18 май, 375 нче; 2018 ел, 24 июль, 592 нче; 2018 ел, 8 сентябрь, 762 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1127 нче; 2019 ел, 19 апрель, 311 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1192 нче; 2020 ел, 11 февраль, 94 нче; 2020 ел, 17 март, 196 нчы; 2020 ел, 27 май, 429 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә, III бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«III. Министерлык функцияләре

3.1. Министрлык төп – юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашыру өчен җавап бирә (02.03*);

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.